## АУЛАК ӨЙ КИЧӘЛӘРЕ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Әй, дусларым! Габдрахман! Габдрәшит!
Ник утырасыз боек?
Күрше кызлар аулак өй ясыйлар бит,
Әйдә, шунда барыйык! } 2 тапкыр

Бүген атнакич икән бит,
Кызлар токмач кискәннәр.
Рәхмәт төшсен бу кызларга,
Буйга зифа үскәннәр!

Егетләр килеп җитәләр
Биергә һәм җырларга.
Безне бигрәк үз итәләр –
Рәхмәт төшсен кызларга!

2. Әй, гармунчы дус, утырма йоклап!
Гармуныңны суза төш!
Телләренә бер басып җибәр ныклап,
Кулларыңда бардыр көч! } 2 тапкыр

Ала мәче, кара мәче
Күрше кураларында.
Сикереп төшеп биеп алыйк
Халык араларында.
И биегез, биегез, шул,
Әнә шулай биегез!
Уйнамагач та көлмәгәч,
Нигә монда килдегез?

3. Матур көйләрне сыздыра тальян,
Яшьләр йөзек салалар.
Аулак чакта сөйгән ярлары белән
Үбешеп тә алалар. } 2 тапкыр

Син дә чибәр, мин дә чибәр,
Кашың сикертеп җибәр!
Мине авылның кызлары
Иң чибәр егет диләр.

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Бишәү, алтау, унике.
Унике кыз арасында
Иң чибәре минеке!

4. Әкрен-әкрен биюләр дә бетә,
Аякларны талдырып.

Инде такмак әйтешер вакыт җитә,
Кара-каршы утырып. } 2 тапкыр

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр йомычка.
Ухажёр булып килгәнсез –
Ник йөртмисез подручка?

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр киң каеш.
Үзегезне әллә кемгә
Куясыз, понимаешь!

5. Их, яшь чаклар! Кайда сез, яшь чаклар,
Матур аулак кичәләр,
«Йолдыз санау» белән «морҗа ябулар»,
Без бирешкән вәгъдәләр? } 2 тапкыр

Егетләр шаяртмый калмас,
Кызлар бизәнми калмас.
Егет белән кызлар барда
Уен-көлке һич тынмас!

Биек тауның башларында
Күренәдер бер авыл.
Яшьләр җыелган урында
Бик күңелле була ул.

6. Үтә вакыт, сорап тормый бездән,
Яшьлек тә кайтмас кире.
Тик беркайчан да чыкмас күңелләрдән
Аулак өй кичәләре! } 2 тапкыр

**Молодёжные вечеринки в ауле**

Когда взрослые уезжают в соседний аул повидать родственников, девушки, оставшиеся дома, приглашают в гости молодежь. Песни, танцы до упада, шутки, приколы – все это старинный татарский обычай под названием «Аулак өй».